**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на территории Новонадыровского сельского поселения муниципального образования «Альметьевский муниципальный район» в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных**

В связи с выявлением заболевания бешенством животных и угрозой его распространения в населенных пунктах Республики Татарстан, в соответствии со статьями $3^1$, 17 Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю:**

1. Установить ограничительные мероприятия (карантин) в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных на территориях эпизоотического очага и неблагополучного пункта, определенных пунктом 2 настоящего Указа.

2. Определить:

а) эпизоотический очаг – территория личного подсобного хозяйства по улице Советская, дом 154, села Новое Надырово в Новонадыровском сельском поселении муниципального образования «Альметьевский муниципальный район»;

б) неблагополучный пункт – территория Новонадыровского сельского поселения муниципального образования «Альметьевский муниципальный район».

3. Запретить:

а) в эпизоотическом очаге:

лечение больных восприимчивых животных;

посещение территории посторонними лицами, кроме персонала, выполняющего производственные (технологические) операции, в том числе по обслуживанию восприимчивых животных, специалистов госветслужбы и персонала, привлеченного для ликвидации очага, лиц, проживающих и (или) временно пребывающих на территории эпизоотического очага;

ввоз (ввод), вывоз (вывод) восприимчивых животных, за исключением вывоза восприимчивых животных, вакцинированных против бешенства в течение 179 календарных дней, предшествующих вывозу, в том числе на убой на предприятия по убою животных или оборудованные для этих целей убойные пункты;

перемещение и перегруппировку восприимчивых животных;

снятие шкур с трупов восприимчивых животных;

б) в неблагополучном пункте:

проведение ярмарок, выставок (торгов) и других мероприятий, связанных с перемещением и скоплением восприимчивых животных;

вывоз восприимчивых животных;

отлов диких восприимчивых животных для вывоза в зоопарки.

4. Установить, что карантин подлежит отмене по истечении 60 календарных дней после убоя последнего подозреваемого в заболевании бешенством восприимчивого животного и (или) уничтожения последнего трупа больного восприимчивого животного, проведения иных необходимых мероприятий.

5. Главному управлению ветеринарии Кабинета Министров Республики Татарстан разработать и утвердить план мероприятий по ликвидации бешенства животных на территориях, указанных в пункте 2 настоящего Указа, а также обеспечить его реализацию.

6. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Кабинет Министров Республики Татарстан.

7. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
10 июня 2021 года
№ УП-474

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында**

Хайваннарның котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Әлеге Указның 2 пункты нигезендә билгеләнгән эпизоотия чыганагы һәм имин булмаган пункт территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) эпизоотия чыганагын – «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Яңа Нәдер авыл җирлегендәге Яңа Нәдер авылында Совет урамы 154 нче йортта урнашкан шәхси ярдәмче хуҗалык территориясен;

б) имин булмаган пунктны – «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясен.

3. Түбәндәгеләрне тыярга:

а) эпизоотия чыганагында:

котыру чиренә бирешүчән авыру хайваннарны дәвалауны;

җитештерү белән бәйле (технологик) операцияләрне, шул исәптән котыру чиренә бирешүчән хайваннарга хезмәт күрсәтүче персоналдан, эпизоотия чыганагын бетерүдә катнашучы дәүләт ветеринария хезмәте белгечләре һәм персоналдан, эпизоотия чыганагы территориясендә яшәүче һәм (яисә) вакытлыча торучы затлардан кала территориягә чит кешеләр керүен;

алып киткәнче 179 календарь көн дәвамында котыру чиренә каршы вакцина ясалган котыру чиренә бирешүчән хайваннарны, шул исәптән сугым предприятиеләренә яисә әлеге максатлар өчен җиһазландырылган сугым пунктларына иткә сую өчен алып китүдән тыш, котыру чиренә бирешүчән хайваннарны территориягә алып керүне (кертүне) һәм алып чыгуны (чыгаруны);

котыру чиренә бирешүчән хайваннарны күчереп йөртүне һәм төркемнәргә туплауны;

котыру чиренә бирешүчән хайваннар үләксәләренең тиреләрен салдыруны;

б) имин булмаган пунктта:

ярминкәләр, күргәзмәләр (сату итү) уздыру һәм котыру чиренә бирешүчән хайваннарны күчереп йөртү һәм туплау белән бәйле башка чаралар үткәрүне;

котыру чиренә бирешүчән хайваннарны читкә чыгаруны;

котыру чиренә бирешүчән кыргый хайваннарны зоопаркларга чыгару өчен аулауны.

4. Котыру чире белән авырый дигән шик тудыра торган котыру чиренә бирешүчән соңгы хайван суелган һәм (яисә) котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узгач, башка тиешле чаралар үтәлгәч, карантин бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 2 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә хайваннарның котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 10 июнь
№ ПУ-474